| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 март № 155

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 7 өлеш, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешнең 5 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны әлеге карарга туры китерү турында тәкъдимнәрне өч ай эчендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 март, 155 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан
күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча
региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау
тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 7 өлеш, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешнең 5 нче пункты нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын (алга таба – Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планы) һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнарын (алга таба – Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнары) эшләүгә һәм раслауга таләпләрне билгели.

2. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын эшләү һәм раслау Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү вакытларын конкретлаштыруга, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча планлаштырыла торган хезмәтләр һәм (яки) эшләр төрләрен тәгаенләүгә, дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләүгә, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау күләмнәрен билгеләүгә юнәлдерелгән.

3. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планы һәм Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнары өч елга, күрсәтелгән вакыт чикләрендә еллар буенча бүленеп эшләнә.

4. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын әзерләү һәм раслау үз эченә түбәндәге этапларны ала:

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнары проектларын эшләү;

муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары норматив хокукый актлары белән Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнарын раслау;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын эшләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау.

5. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнары һәм Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планы үз эченә түбәндәге бүлекләрне ала:

1) төп максатлар һәм бурычлар;

2) башкаруда катнаша торган муниципаль берәмлекләр исемлеге;

3) күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре;

4) ресурслар белән тәэмин итү;

5) капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик кыйммәте;

6) тормышка ашыру механизмы;

7) күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау эшләрен башкару өчен подряд оешмаларын сайлап алу тәртибе.

6. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнарына һәм Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

1) күпфатирлы йорт урнашкан муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) исеме;

2) төрен һәм катларын, адресын, номерын (яки йортның башка идентификаторын (идентификаторларын)) күрсәтеп, күпфатирлы йортлар исемлеге;

3) күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге;

4) күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яки) эшләр башкаруның планлаштырыла торган күрсәткечләре;

5) күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр кыйммәте;

6) капиталь ремонт эшләре тәмамлануның планлаштырылган чоры, ләкин капиталь ремонт эшләре планлаштырылган елдан соң килә торган 31 декабреннән дә соң түгел;

7) урыннар милекчеләренең тиешле елда күпфатирлы йортта капиталь ремонт өчен түләүгә тотарга планлаштырыла торган кертемнәре күләме;

8) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күләме;

9) күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулы;

10) кыска вакытлы планнарга кертелергә тиешле башка мәгълүматлар, шул исәптән законнарда каралган.

7. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бу Тәртипкә теркәлгән 1, 2, 3 нче кушымталардагы форма буенча бирелә.

8. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планында күпфатирлы йортлар исемлеге муниципаль берәмлекләр буенча бүлеп күрсәтелә.

9. Вәкаләтле орган Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын тормышка ашыра башлау елына кадәр килә торган елның 15 октябренә кадәр муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына түбәндәге мәгълүматны җиткерә:

1) Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын тормышка ашыру елына капиталь ремонт үткәрелергә тиешле күпфатирлы йортлар исемлеге, Программада күздә тотылган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүнең тиешле елына «Торак фонды мониторингы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан әлеге йортлар турындагы мәгълүматларны алып;

2) күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауга әлеге йорттагы урыннар милекчеләреннән кертемнәрнең фаразлана торган күләменнән һәм дәүләт ярдәме күләменнән кушылып чыга торган Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын тормышка ашыру елына чыгымнарның финанслар белән тәэмин ителеш акчасының планлаштырыла торган күләме.

10. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, күпфатирлы йорт белән идарә итүне яки күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан әлеге йортның уртак мөлкәтенә үткәрелгән карап тикшерү нәтиҗәләре буенча һәрбер күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен эшләнгән һәм расланган смета документлары һәм бу Тәртипнең 9 нчы пунктында күздә тотылган мәгълүмат нигезендә, Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын тормышка ашыру елына кадәр килә торган елның 20 ноябренә кадәр Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнарын раслыйлар.

11. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнарын раслаган көннән соң җиде эш көне эчендә аларны Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын эшләү өчен вәкаләтле органга җибәрә.

12. Вәкаләтле орган Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын эшли һәм аны тормышка ашыра башлау елына кадәр килә торган елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

13. Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планы Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын тормышка ашыра башлау елына кадәр килә торган елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

______________________________

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планы кысаларында капиталь ремонт үткәрелергә тиешле күпфатирлы йортлар исемлеге

| Т/с | КФЙ адресы* | Ел | | Диварлар материалы | Катлар саны | Подъездлар саны | КФЙ гомуми мәйданы – барлыгы | КФЙ урыннары мәйданы | | Кыска вакытлы планны раслаган көнгә КФЙта теркәлгән анда яшәүче кешеләр саны | Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулы | Эшләр төрләре | Капиталь ремонт кыйммәте | | | | | КФЙ урыннарының гомуми мәйданының 1 кв.метрын капиталь ремонтлауның чагыштырма кыйммәте | КФЙ урыннарының гомуми мәйданының 1 кв.метрын капиталь ремонтлауның чик кыйммәте | Эшләрне тәмамлауның планлаштырылган көне |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | эксплуатациягә кертү | соңгы капиталь ремонт тәмамлану | | | | | барлыгы | шул исәптән гражданнар милкендә булган торак урыннар | | | | барлыгы | шул исәптән: | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы исәбеннән | җирле бюджет акчасы исәбеннән | УМШ, башка кооперативлар яки КФЙтагы урыннар милекчеләре акчасы исәбеннән | башка чыганаклар исәбеннән | | | |
| | | | | | | | кв.метр | кв.метр | кв.метр | кеше | махсус счет/ төбәк операторы счеты | | сум | сум | сум | сум | сум | сум/кв.метр | сум/кв.метр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |

---

* Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 2 биттә.

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Субъект буенча барлыгы | | X | X | X | X | X | | | | | | | | | | | | | | |
| МБ$_1$ | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| ... | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| n | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| МБ$_1$ буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| МБ$_2$ | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| n+1 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| МБ$_2$ буенча барлыгы | | X | X | X | X | X | | | | | | | | | | | | | | |
| n+1 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:
КФЙ – күпфатирлы йорт;
УМШ – урыннар милекчеләре ширкәте.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына кертелгән күпфатирлы йортларның эшләр төрләре буенча реестры

| Т/с | Күпфатирлы йортның адресы | Капиталь ремонт кыйммәте – барлыгы | Россия Федерациясе Торак кодексының 168 ст. 1 өлештә билгеләнгән хезмәтләр һәм (яки) эшләр төрләре | | | | Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актында билгеләнгән хезмәтләр һәм (яки) эшләр төрләре: | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ________ (хезмәтләр һәм (яки) эшләр исеме) | | … | | ________ (хезмәтләр һәм (яки) эшләр исеме) | | … | |
| | | сум | күләме | суммасы | … | … | күләме | суммасы | … | … |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | … | … | … | … | n | n+1 |
| МБ$_1$ | | | | | | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | |
| … | | | | | | | | | | |
| МБ$_1$ буенча барлыгы | | | | | | | | | | |
| МБ$_2$ | | | | | | | | | | |
| n | | | | | | | | | | |
| n+1 | | | | | | | | | | |
| МБ$_2$ буенча барлыгы | | | | | | | | | | |
| Субъект буенча барлыгы | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | КФЙ* гомуми мәйданы – барлыгы | Кыска вакытлы планны раслаган көнгә КФЙта теркәлгән анда яшәүче кешеләр саны | КФЙ саны | | | | | Капиталь ремонт кыйммәте | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | бар-лыгы | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | бар-лыгы |
| | | кв.метр | кеше | берәмлек | берәмлек | берәмлек | берәмлек | берәм-лек | сум | сум | сум | сум | сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | Өч ел буенча субъект буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | |
| | n ел буенча субъект буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | |
| | $МБ_1$ | | | | | | | | | | | | |
| | ….. | | | | | | | | | | | | |
| | $МБ_n$ | | | | | | | | | | | | |

* КФЙ – күпфатирлы йорт.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | n+1 ел буенча субъект буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | |
| | $МБ_1$ | | | | | | | | | | | | |
| | ….. | | | | | | | | | | | | |
| | $МБ_n$ | | | | | | | | | | | | |
| | n+2 ел буенча субъект буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | |
| | $МБ_1$ | | | | | | | | | | | | |
| | ….. | | | | | | | | | | | | |
| | $МБ_n$ | | | | | | | | | | | | |

F:\KARAR\2017\155_3.docx